Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

28 сентябрь 2021 ел № 76

Авыл хуҗалыгы җирләрен хосусыйлаштыру вакытына билгеләнгән җир кишәрлекләрен гражданнар милкенә түләүсез тапшыруның уртача район нормасын билгеләү турында

«Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең әйләнеше турында» 2002 елның 24 июлендәге 101-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Җир кодексының 40 статьясындагы 2 пункты һәм Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставы нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы территориясендә авыл хуҗалыгы җирләрен хосусыйлаштыру вакытына билгеләнгән гражданнар милкенә җир кишәрлекләрен бушлай тапшыруның уртача район нормасын 6,56 гектар күләмендә расларга.

2. Район башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту район Советының икътисади үсеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм муниципаль милек мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә (Мингазов И.М.) йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов